**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019 елның 9 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 9 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2019 елда 4000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күпбалалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

- Майская Горка авылында юл ремонтлау

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 26 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 15 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 15 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2019 елда 4000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күпбалалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

- Майская Горка авылында юл ремонтлау

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Майская Горка авыл җирлеге сайтында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы С.Н. Шумилов